МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.10.2023 г. Казань № 224

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июлендәге 273 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карарына һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында « 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июлендәге 273 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2.1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1. КУЭ субъекты, алдагы календарь ел нәтиҗәләре буенча кече яки урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләре арасында (инвалид булып торучы шәхси

эшкуарларга карата шәхси эшкуарның үзе исәпкә алынган кече яки урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләре арасында) мондый категорияләрнең (бер яки берничә шундый категория) теләсә кайсына караган затларның уртача исемлек саны кимендә илле процент (шундый категориягә караган кимендә ике зат) булу, ә мондый категорияләрнең (шундый бер яки берничә категориянең) теләсә кайсына караган затлар хезмәтенә түләү чыгымнары хезмәткә түләү чыгымнарында кимендә егерме биш процент өлешен алып тору шарты белән, гражданнарның түбәндәге категорияләрен эш белән тәэмин итә:»;

түбәндәге эчтәлекле 1.2.1[1] пунктын өстәргә:

«1.2.1[1] КУЭ субъекты – инвалид булган һәм эшкуарлык эшчәнлеген эшчеләрне җәлеп итмичә алып баручы шәхси эшкуар.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының гаризалары белән эшләү өчен җаваплы булып «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең Социаль өлкә инновацияләре үзәге тора.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып, Регламентның 13 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында карар яки КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар тора. Бу документларда тәртип номеры һәм датасы була.

2.3.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысуллары:

шәхсән килгән очракта;

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә (алга таба – «Интернет» челтәре) кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат - телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) аша.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша яки адреслы сайлап алу механизмы һәм КУЭ субъектлары тарафыннан ярдәм чараларын һәм махсус сервисларны дистанцион алу мөмкинлеге белән цифрлы платформа функционалын кулланып, документларның электрон үрнәкләре формасында (реквизитларын саклап, документларны сканер аша уздыру юлы белән

электрон формага үзгәртелгән кәгазь документлар) тапшырылган булса, Республика порталында яки цифрлы платформада шәхси кабинетта чагылдырылган дәүләт хезмәте эшләр номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән башлап эш көннәрендә санала торган 30 көнлек срокта күрсәтелә.

Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән гариза һәм башка документлар, КУЭ субъекты тарафыннан Социаль өлкә инновацияләре үзәгенә ел саен агымдагы календарь елның 1 июненә кадәрге срокта узган календарь ел белешмәләре буенча мондый социаль предприятиеләр турындагы белешмәләрне агымдагы елның 10 июленә кадәр КУЭ субъектларының бердәм реестрына кертү өчен түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла:

Республика порталы аша электрон формада;

адреслы сайлап алу механизмы һәм КУЭ субъектлары тарафыннан ярдәм чараларын һәм махсус сервисларны дистанцион алу мөмкинлеге белән цифрлы платформа функционалын кулланып, документларның электрон үрнәкләре формасында (реквизитларын саклап, документларны сканер аша уздыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь документлар);

Социаль өлкә инновацияләре үзәгендә шәхсән кабул итү яки тапшыру турында белдерү белән, почта аша хат итеп юллау.

КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану максатыннан, алдагы календарь ел мәгълүматлары буенча, гариза һәм Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән башка документлар шулай ук агымдагы календарь елның 2 июненнән 31 декабренә кадәр КУЭ субъектлары тарафыннан шундый социаль предприятиеләр турында мәгълүматларны КУЭ субъектларының бердәм реестрына кертү өчен, КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында Министрлык тарафыннан карар кабул ителгән айдан соң киләсе икенче айның 10 нчы көнендә тапшырыла ала.

Гаризада һәм Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән башка документларындагы белешмәләр мондый гариза һәм документлар бирелгән көнгә гамәлдә булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртү Россия Федерациясенең шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге законнары нигезендә башкарыла. Мөрәҗәгать итүченең гаризадагы имзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын раслый.

КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында яки КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар гаризада күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы адресына җибәрелә, яки мондый карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә Республика порталындагы шәхси кабинетта урнаштырыла, яки мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) мөрәҗәгать итү көнендә махсус бирелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Министрлык сайтында һәм Республика порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында мөрәҗәгать итүче – шәхси эшкуар, мөрәҗәгать итүче – юридик зат җитәкчесе яисә закон, башка хокукый акт яисә юридик затның гамәлгә кую документы нигезендә юридик зат исеменнән яисә ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле мөрәҗәгать итүче (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган гариза (алга таба – гариза). Гариза үрнәге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

2) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон), $24^1$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән шартка (шартларга) бәйле рәвештә аңа ярашлы рәвештә, КУЭ субъекты үзен социаль предприятие дип тану өчен мөрәҗәгать итү өчен бирә торган Регламентның 2.6.1.1-2.6.1.5 пунктларында күрсәтелгән документлар;

3) мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле затының гаризага һәм (яки) Регламентның 2.6.1.1-2.6.1.5 пунктларында күрсәтелгән документларга кул кую хокукын раслаучы ышаныч кәгазе (документлар ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил тарафыннан тапшырылган очракта).

КУЭ субъекты социаль эшкуарлык өлкәсендә үзе башкара торган эшчәнлекнең характеры һәм үзенчәлекләре турында киңәйтелгән белешмәләр бирү өчен әлеге пунктта каралган документларга өстәмә рәвештә, шулай ук социаль йогынты турында хисап та тапшырырга хокуклы. Социаль йогынты турында хисапның киңәш ителә торган үрнәге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге хисапның тапшырылмавы КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.1.1. 209-ФЗ номерлы федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган шартларга туры килгән КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) гариза биргән көнгә гамәлдә булган мөрәҗәгать итүченең штат расписаниесе күчермәсе (КУЭ субъекты белән җинаять-башкару системасы учреждениесе арасында гражданлык-хокукый килешү төзү очрагыннан тыш);

2) 209-ФЗ номерлы федераль законның $24^1$ статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләре күчермәләре, җәзаны үтәү чорында ирегеннән мәхрүм итүгә һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затлардан тыш. Ирektән мәхрүм ителүгә һәм җәзаны үтәү чорында мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларның мәшгульлеген тәэмин иткәндә, җинаять-башкару системасы учреждениесе белән кече яки урта эшкуарлык субъектының гражданлык-хокукый килешүе күчермәсе бирелә;

3) мөрәҗәгать итүченең хезмәткәрләрен 209-ФЗ номерлы федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категория-

ләренә кертүне раслаучы документлар күчермәләре, Регламентка 3 нче кушымтада каралган тәкъдим ителгән исемлеккә ярашлы рәвештә (җинаять-башкару системасы учреждениесе белән кече яки урта эшкуарлык субъектының гражданлык-хокукый килешүен төзү очрагыннан тыш);

4) 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре арасыннан мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләренең саны һәм хезмәт хакы турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән;

5) 209-ФЗ номерлы федераль законның 24.1 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык (шәхси мәгълүматлар вәкаләтле органга КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану максаты белән бирелә, дип күрсәтеп), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләренә ярашлы рәвештә язма рәвештә бирелә, кече яки урта эшкуарлык субъекты белән җинаять-башкару системасы учреждениесе арасында гражданлык-хокукый килешүен төзү очрагыннан тыш (Регламентка 9 нчы кушымта);

6) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (Регламентка 10 нчы кушымта) һәм таратырга рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (Регламентка 11 нче кушымта), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләренә ярашлы рәвештә язма рәвештә бирелә.

2.6.1.2. 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган шартларга туры килә торган КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре исәбендәге гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сату турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста керемнең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.

2.6.1.3. 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган шартларга туры килә торган КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек юнәлешләренә туры китереп, мондый гражданнар өчен аларның тормыш-көнкүрешендәге чикләүләрне җиңәргә яисә компенсацияләргә мөмкинлек бирүче шартлар тудыру, шулай ук җәмгыять

тормышында башка гражданнар белән бертигез дәрәҗәдә катнашу мөмкинлеге тудыру максатларында, 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре өчен билгеләнгән товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында мәгълүматлар. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста кеременең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.

2.6.1.4. 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 4 өлешенең 1 пунктында каралган шартларга туры килгән КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек төрләре арасыннан җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә ярдәм итүче иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге Регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан 209-ФЗ номерлы федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста кеременең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.

2.6.1.5. Гаризада һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән башка документларындагы белешмәләр мондый гариза һәм документлар бирелгән көнгә гамәлдә булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртү Россия Федерациясенең шәхси мәгълүматлар өлкәсендәге законнары нигезендә башкарыла. Мөрәҗәгать итүченең гаризадагы имзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын раслый.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелә торган мәгълүмат:

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаиләнең статусын раслаучы документлар. Рәсми

мөрәҗәгать Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасына җибәрелә (алга таба – БДСТМС);

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

интернат-балалар йортында булу турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

гражданинны (гражданинның гаиләсен) аз керемле (аз керемле) дип тануны раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алуны раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать «Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – ГХАТ БДР) җибәрелә;

ата-ананың берсенең үлемен раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

туу турында таныклыкта баланың әтисе турында язуның әни сүзләреннән теркәлүен раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

бала тууын раслаучы, «Атасы» графасында сызык торган документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың тууын (уллыкка, кызлыкка алынуын) раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе. Рәсми мөрәҗәгать «Правосудие» дәүләт автоматлаштырылган системасына (алга таба – «Правосудие» ДАС) җибәрелә;

инвалид балага опека, попечительлек билгеләүне раслаучы документлар (опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү яки опека һәм попечительлек органының опекун яки попечитель билгеләү турындагы акты). Рәсми мөрәҗәгать «Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – «Опека һәм попечительлек» АМС) җибәрелә;

пенсия билгеләү турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать Россия Социаль фондының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – РСФ АМС) җибәрелә;

Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яшендәге гражданин статусын алуны раслаучы документ (картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнгән яшькә кадәр биш ел дәвамында). Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

физик затларда физик һәм (яки) психологик үсештә кимчелекләр билгеләүне раслаучы документ (эш бирүче тарафыннан билгеләнә). Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

хәрби билет булуын раслаучы документ. Сорау «Горизонт-МР» гражданнар турында автоматлаштырылган мәгълүмат системасына җибәрелә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында белешмә яки хөкем ителү һәм (яки) җинаять эзәрлекләү факты булу (булмавы) яки җинаять

эзәрлекләүләрен туктату турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

качак яки мәҗбүри күченүче статусын раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар. Рәсми мөрәҗәгать «Социаль яклау» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – «Социаль яклау» АМС) җибәрелә.

мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге пунктта күрсәтелгән документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Республика порталы аша электрон формада;

2) адреслы сайлап алу механизмы һәм КУЭ субъектлары тарафыннан ярдәм чараларын һәм махсус сервисларны дистанцион алу мөмкинлеге белән цифрлы платформа функционалын кулланып, документларның электрон үрнәкләре формасында (реквизитларын саклап, документларны сканер аша уздыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь документлар);

3) Социаль өлкә инновацияләре үзәгендә шәхсән кабул итү яки тапшыру турында белдерү белән, почта аша хат итеп юллау.

2.6.4. Гариза Республика порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БИАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар, шул исәптән ышаныч кәгазьләре 50 Мбайттан артмаган үлчәмдә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) интерактив гариза формасында мәҗбүри кырларның дөрес тутырылмавы;

2) интерактив гаризада һәм тапшырылган документларда бер-берсенә каршы килә торган мәгълүматлар булуы;

3) гаризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) һәм электрон формадагы башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы;

4) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

5) мөрәҗәгать итүче булып тормаган затның мөрәҗәгать итүе;

6) Регламентның 2.6 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яки берничә документ булмавы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 12 нче кушымтада билгеләнгән формага туры китереп рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетка җибәрелә.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Республика порталында яки Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның комплектсызлыгы (Регламентның 2.6.1.1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш) һәм (яки) андагы мәгълүматларның дөрес булмавы, һәм (яки) документларның электрон үрнәкләрендә документ текстының тулы күләмдә укырга яки аның реквизитларын танырга мөмкинлек бирмәве;

Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны, шулай ук 3.6 пункты нигезендә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең Социаль өлкә инновацияләре үзәгеннән алынган белешмәләрне һәм мәгълүматларны карау барышында мөрәҗәгать итүчене 209-ФЗ номерлы федераль законның $24^1$ статьясының 2 һәм (яки) 4 өлешләрендә каралган социаль предприятие дип тану шартларына туры килмәве ачыкланган очракта, шул исәптән КУЭ субъектларының бердәм реестрында мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр булмаса.

документларны тапшыру өчен Регламентның 2.4 пунктында билгеләнгән срок бозылган очракта.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентның 13 нче кушымтасында билгеләнгән формага ярашлы рәвештә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм гаризада күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы адресына яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә яки мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) мөрәҗәгать иткән көнне кәгазьдә тапшырыла.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында яки Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне теркәлә.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы, гаризага алынган номер беркетеп һәм аны алу датасын күрсәтеп, документ әйләнешенең билгеләнгән системасында теркәлә.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла. Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.

Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

2) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

3) инвалидларга, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, тоткарлыксыз хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен кирәкле җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльнең нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны кабатлап тору;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ

рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгында билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, сукырларны йөртә торган этне кертү;

7) инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан бетерүдә ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.13.2. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәте күрсәтү урынына транспорт белән үтеп керә алу мөмкинлеге;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның вазыйфаи затлары белән үзара бәйләнешкә керү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара бәйләнешкә керү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.3. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге 72 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша гамәлгә ашырылмый.»;

3.4.2 пунктның уникенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5, 3.6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү. 3.5.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.5.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып).

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаиләнең статусын раслаучы документлар. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

интернат-балалар йортында булу турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

гражданинны (гражданинның гаиләсен) аз керемле (аз керемле) дип тануны раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать БДСТМС җибәрелә;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алуны раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

ата-ананың берсенең үлемен раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

туу турында таныклыкта баланың әтисе турында язуның әни сүзләреннән теркәлүен раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

бала тууын раслаучы, «Атасы» графасында сызык торган документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың тууын (уллыкка, кызлыкка алынуын) раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать ГХАТ БДР җибәрелә;

баланың билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе. Рәсми мөрәҗәгать «Правосудие» ДАС җибәрелә;

инвалид балага опека, попечительлек билгеләүне раслаучы документлар (опеканы яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү яки опека һәм попечительлек органының опекун яки попечитель билгеләү турындагы акты). Рәсми мөрәҗәгать «Опека һәм попечительлек» АМС җибәрелә;

пенсия билгеләү турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яшендәге гражданин статусын алуны раслаучы документ (картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнгән яшькә кадәр биш ел дәвамында). Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә. Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

физик затларда физик һәм (яки) психологик үсештә кимчелекләр билгеләүне раслаучы документ (эш бирүче тарафыннан билгеләнә). Рәсми мөрәҗәгать РСФ АМС җибәрелә;

хәрби билет булуын раслаучы документ. Сорау «Горизонт-МР» гражданнар турында автоматлаштырылган мәгълүмат системасына җибәрелә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында белешмә яки хөкем ителү һәм (яки) җинаять эзәрлекләү факты булу (булмавы) яки җинаять эзәрлекләүләрен туктату турында белешмә. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

качак яки мәҗбүри күченүче статусын раслаучы документ. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар. Рәсми мөрәҗәгать «Социаль яклау» АМС җибәрелә;

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда. Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

3.6.1. Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне – дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»

3.8.10 пунктының икенче абзацында «1 май» сүзләрен «1 июнь» сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче кушымтада «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алмаштырырга;

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры Н.В.Кондратовага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

**ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮДӘ ТОТУНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ОРГАННАР ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР**

**1. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Генераль директорның беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фондының «Минем бизнес» үзәге җитәкчесе | +7 (843) 222-90-60, өст. 101 | Linara.Burhanova@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фондының Социаль өлкә инновацияләре үзәге җитәкчесе | +7 (843) 222-90-60, өст. 124 | Mihail.Untura@tatar.ru |

**2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры | +7 (843) 524-91-05 | Kondratova.Natalya@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны үстерү департаментының Эшкуарлыкны үстерү идарәсе башлыгы | +7 (843) 524-91-60 | Mariya.Suhovaya@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны үстерү департаментының Эшкуарлыкны үстерү идарәсенең финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | +7 (843) 524-90-93 | Ruslan.Hamidullin@tatar.ru |